КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 16 ноябрь г.Казань № 1000

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2015 ел, 12 сентябрь, 665 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2015 ел, 12 сентябрь, 665 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 3 апрель, 207 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Сатып алулар план-графигына товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр исемлеге кертелә; әлеге товарларны, эшләрне, хезмәтләрне сатып алу Контракт системасы турындагы законның 24 статьясындагы 2 өлештә күрсәтеп үтелгән тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) билгеләү алымнарын куллану юлы белән, бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, үтәүчедән), шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Контракт системасы турындагы законның 111 статьясы нигезендә билгеләнә торган тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) билгеләү алымын куллану юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

9 нчы һәм 10 нчы пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Сатып алулар план-графигына сатып алуның һәр объекты буенча үзгәрешләр кертү сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына сатып алуны гамәлгә ашыру турында белдерү урнаштыру яки тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) ябык ысул белән билгеләүдә катнашу өчен чакыру кәгазе җибәрү (бу Тәртипнең 10 – $10^2$ нче пунктларында күрсәтелгән очраклардан тыш) көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, әмма сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына кертелә торган үзгәрешләр Контракт системасы турындагы законның 21 статьясындагы 15 өлеш нигезендә урнаштырылганнан соң гына гамәлгә ашырылырга мөмкин.

10. Сатып алулар Контракт системасы турындагы законның 82 статьясы нигезендә гуманитар ярдәм күрсәтү йә табигый яки техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр салган зыяннарны бетерү максатларында бәяләрне сорап алу юлы белән гамәлгә ашырылган очракта, сатып алулар план-графигына үзгәрешләр кертү – сатып алуларда катнашучыларга бәяләр бирү турында сорау җибәрелә торган көндә, ә бердәнбер тәэмин итүчедән (подрядчыдан, үтәүчедән) сатып алу гамәлгә ашырылган очракта, Контракт системасы турындагы законның 93 статьясындагы 1 өлешнең 9 нчы пункты нигезендә контракт төзелгән көндә гамәлгә ашырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле $10^1$ нче һәм $10^2$ нче пунктлар өстәргә:

«$10^1$. Контракт системасы турындагы законның 55 статьясындагы 2, 4 – 6 өлешләр, $55^1$ статьясындагы 4 өлеш, 71 статьясындагы 4 өлеш, 79 статьясындагы 4 өлеш, $82^6$ статьясындагы 2 өлеш, 83 статьясындагы 19 өлеш, $83^1$ статьясындагы 27 өлеш һәм 93 статьясындагы 1 өлеш нигезендә сатып алулар гамәлгә ашырылган очракта (бу Тәртипнең 10 нчы пунктында күрсәтелгән очрактан тыш), сатып алулар план-графигына сатып алуның һәр шундый объекты буенча үзгәрешләр кертү сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына тиешле сатып алуны гамәлгә ашыру турында белдерү урнаштыру яки тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) ябык ысул белән билгеләүдә катнашырга чакыру кәгазе җибәрү көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырылырга мөмкин.

$10^2$. Әгәр дә Контракт системасы турындагы закон нигезендә сатып алуны гамәлгә ашыру турында белдерү урнаштыру яки тәэмин итүчене (подрядчыны, үтәүчене) билгеләүдә катнашырга чакыру кәгазе җибәрү каралмаган булса, план-графикка сатып алуның һәр шундый объекты буенча үзгәрешләр кертү контракт төзү көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырылырга мөмкин.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин